РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ
БЮРГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОЕРГАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

26.04.2023 ел № 1-69

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Боерган авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен
карау регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 октябрендәге 1-48 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентын раслау турында»гы карары белән расланган (05.03.2018 № 47-1, 29.09.2018 № 59-2, 29.07.2019 № 73-1 карарлары редакцияләрендә) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентына киләсе үзгәрешләрне кертергә:

1.1. VII бүлектә:

7.4.2 пунктын үзгәртергә һәм киләсе редакциядә бәян итәргә:

«7.4.2. 15 көнгә кадәр карау срогы белән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау турында Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Рәисе мөрәҗәгатьләрен карау буенча йөкләмәләрнең үтәлеше аерым контрольгә куела.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

ТР Буа муниципаль районы
Боерган авыл җирлеге башлыгы И.В. Малышева